**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең Кара- Ширмә торак пунктының гражданнар җыены буенча**

**2019 елның 7 декабре** **Кара- Ширмә авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Иске Җөри авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 7 декабрендә Кара-Ширмә торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең Кара-Ширмә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Кара-Ширмә авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- юлларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту, юл буйларындагы үләннәрне чабу;
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау;
- игъланнар тактасы сатып алу һәм урнаштыру;

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 155 кеше кертелгән;

җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 90 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:

гражданнар җыенында катнашучы 90 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең Кара-Ширмә торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – дөрес.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегенең Кара-Ширмә торак

пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 500 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны Кара-Ширмә авылында чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- юлларны ремонтлау, юлларны кардан чистарту, юл буйларындагы үләннәрне чабу;
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау;
- игъланнар тактасы сатып алу һәм урнаштыру .
- кабул ителгән.

3.Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Иске Җөри авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Җөри авыл җирлеге Башлыгы: Р. Р. Мараков